# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Зур Тигәнәле авыл җирлеге Зур Тигәнәле авыл торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 елның 12 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 12 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча “Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә Зур Тигәнәле авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Зур Тигәнәле авылында урамнарны яктыртуны карап тоту (урам фонарьлары, исәпкә алу приборлары, таймерлар, СИП чыбыклары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- су этем манарасы өчен насослар сатып алу;
- тракторны карап тоту һәм ремонтлау (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- су этем манарасына хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 380 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 285 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 285 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлегендәге Зур Тигәнәле авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны танырга: «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Зур Тигәнәле авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Зур Тигәнәле авылында урамнарны яктыртуны карап тоту (урам фонарьлары, исәпкә алу приборлары, таймерлар, СИП чыбыклары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- су этем манарасы өчен насослар сатып алу;
- тракторны карап тоту һәм ремонтлау (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- су этем манарасына хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Зур Тигәнәле авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru), кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы М.Ә.Гатин